МКУ «Управление Алькеевского МР РТ
Муниципальная бюджетная организациядополнительного образования «Дом детского творчества» Алькеевского муниципального района

Рассмотрено на педагогическом совете
Протокол № 1 от 29 августа 2023г.

Утверждаю
Директор МБО ДО «Дом детского творчества»
_____________ А.А.Гайфуллина
Приказ ДДТ № 37 от 01.09.2023г.
МБОУ «Базарно-Матакская средняя общеобразовательная школа» Алькеевского муниципального района Республики Татарстан
_____________ Л.З.Абдрахманова

Дополнительная общеобразовательная
общеразвивающая программа
художественной направленности
**«Татар драма фольклоры»**
Возраст обучающихся 10-14 лет
Срок реализации: 3 года

Автор-составитель:
Фаттахова Миляуша Габдрауфовна
Педагог дополнительного образования

с. Базарные Матаки 2021г.

Эчтәлек

Бит.

Аңлатма язуы………………………………………………………. 3-6

Уку планы

1нче ел укыту планы……………….. …………… 6-7

2 нче ел укыту планы ……………………………….. 6-7

3 нче уку елы……………………………………….. 6-7

Уку планының эчтәлеге

1 нче уку елы программасы эчтәлеге ……………………………….7

2 нче уку елы программасы эчтәлеге ……………………………….8

3 нче уку елы программасы эчтәлеге ……………………………….9

Программаны үтәү өчен методик һәм материаль– техник база.......................9

Укытучы өчен әдәбият исемлеге.......................................................................10.

Календарь-уку графигы …………………..................................................... 11-29

**Аңлатма язуы.**

Бу оешма укучыларның артистлык сәләтен, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен, логик фикерләүләрен үстерү, татар халык авыз иҗатына, драма жанрына һәм театр сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү максатыннан чыгып оештырылды. “Драма” түгәрәге, исеменнән үк күренгәнчә, театр, сәнгать, җыр-бию яратучы укучыларны туплады. Бу түгәрәк шулай ук сәхнә серләренә төшенү, тамашачылар алдында үз-үзеңне тотарга өйрәнү бурычларын үз эченә ала. Ул 2015 нче елның сентябрь аенда яңа программа белән эшли башлады. Бала үз эшчәнлегенең кешеләргә кирәклеген, җәмгыятькә файдасын тоярга , шәхси канәгатьләнү сизәргә тиеш. Шуңа күрә, укучыларда сәнгатькә, иҗатка, әдәбиятка мәхәббәт, бер- берсенә ихтирам хисләре тәрбияләү, матурлыкны, нәфислекне күрә белергә өйрәтүне татар халкының үткән мирасын, фольклорын өйрәнүне дә максат итеп алдым..

Һәр халык үзенә хас булган, гореф-гадәтләргә бай. Соңгы вакытта туган телебезгә, шулай ук борынгыдан килгән йолаларга игътибар бик нык артты, чөнки татар халкының, башка халыклар кебек үк тарихы, үткәне бик бай, йола-бәйрәмнәре һәм уеннары да күп төрле.

Түгәгрәк программасын төзгәндә, укучыларны шушы халык бәйрәмнәре һәм йолалары үрнәгендә тәрбияләү, җыр-биюләрне, такмак-такмазаларны өйрәтү, шулар аша дуслык хисләре тәрбияләү, милли хисләр, туган җиргә мәхәббәт хисләре тәрбияләү алгы планга куелды.

Түгәрәктә йөрүче укучыларны балалар шагыйрьләре, әсәрләре белән тирәнрәк тыныштыру, аларның әсәрләрен күбрәк уку теләге уяту максатлары да күздә тотылды.

Укучылар шулай ук үткән темалар ярдәмендә иҗади эш итеп шигырь, әдәби әсәр, мәсәл укырга өйрәнеп, сәхнәдә күрә белү, тыңлый һәм ишетә белү күнекмәләрен үстерә ала.

Түгәрәккә йөрүче укучылар югарыда күрсәтелгән белем һәм күнекмәләрне камилләштерергә тиеш.

**Программаның актуальлеге**

Түгәрәк дәресләрендә татар теле, әдәбияты, рәсем, җыр сәнгате, уеннар һәм сәхнә әсәрләре бәйләнештә бирелә. Дәресләр халкыбызның гореф-гадәтләрен, әдәбиятын, мәдәниятын өйрәнүгә нигезләнә.

Укучыларның активлыгын, иҗади эшчәнлеген, кызыксынучанлыгын үстерүгә күнекмәләр формалаштыруга төрле иҗади биремнәр, күнегүләр бирелә, эзләнү методы кулланыла. Программа өч елга исәпләнгән.

"Хәтердән башка йолалар, тәрбиядән башка рухи хәзинә, рухи хәзинәдән башка шәхес, ә шәхестән башка халык - тарихсыз"- дип әйтелә халыкта.

Бала күңелен ап- ак кәгазь белән чагыштыралар. Шул кәгазьгә ничек итеп матурлык, шәфкатьлелек бөртекләрен чәчәргә соң? Әлбәттә, әдәбият- сәнгать аша. Әдәбият , сәнгать белән кызыксынган , китапларны чын күңеленнән яратып укыган баланың белеме дә тирәнрәк, күңеле дә баерак була.Аның күркәм эшләр башкарырга омтылышы да көчәя.

Ә бүген халкыбыз милли традицияләрен торгызу, саклау һәм киләчәк буыннарга тапшыру өчен мөмкинлекләр зур. Кешелек туплаган рухи байлык, әдәп- әхлак кагыйдәләрен үтемле итеп җиткерү өчен әби- бабайларыбызның, төрле авырлыклар белән яшәүләренә карамастан сынмавы, сабыр , инсафлы, мәрхәмәтле булып калуын җиткерү кирәк. Бу максаттан халкыбыз бәйрәмнәре- шәхесне иҗтимагый тормыш таләпләренә күнектерү чарасы. Алар һәр кешенең йөрәк түрендә саклана, үз туган ягына тарта. Татар халкының уй, холкы, фикере, барлык йолалары, гореф-гадәтләре, традицияләре үзе бер тәрбия ысулы булуын күрсәтә. Аларны өйрәнү балаларның рухи үсешенә этәргеч була. Баланың гаиләдә, коллективтагы тәрбияви нормалары, кагыйдәләре халык педагогикасына салынган. Һәр халыкның милли мәдәнияте-ул табигать көчләренә баш ию дип әйтергә була.

Халкыбызның үткәне халык авыз иҗаты үрнәкләрендә, аның археологик казылмаларында, этнографик традицияләрендә күренә.Традиция - ул милләтнең рухи һәм хезмәт тәҗрибәсен буыннан буынга тапшыру төре. Республикага исем биргән халыкның телен һәм мәдәниятен өйрәнү - ул башка милләт мәдәниятен танып белү генә түгел, ә үз, туган ягың мәдәниятен аңлау ул. Башка телләрне өйрәнү үз телеңнең үзенчәлекләрен яхшырак аңларга ярдәм итә, башка яктан карарга киң мөмкинлекләр ача. Хәзергесе чорда Россия һәм Татарстан күләмендә милли мәдәнияткә игътибар арта бара. Халык мәдәнияте - ул милләтебезнең йөзе, рухи хәзинәсе, җәмгыятьнең байлыгы. Кече яшьтәге мәктәп укучыларын милли тәрбия һәм мәдәнияте белән таныштыру төрле тәрбия алымнарына нигезләнеп башкарыла. Иң киң таралган ярдәмче чыганагыбыз булып балалар фольклорын әйтергә була. Ул- тән хәрәкәтләрен ритмга,көйгә салучы үзенә бер төр иҗат. Аларның нәфислек тойгыларын, зиһен һәм хыял йөгереклеген, зәвыкларын үстерү һәм шуларның барысы бергә бала шәхесе өчен тәрбияви әһәмияткә ия. Бармак уеннары, санамышлар, алдавыч әкиятләр, уеннар- болар барысы да бала өчен кызык.

Татар халык уеннары балаларның иң яраткан шөгыле. Ул уеннар тизлек, зирәклек, җитезлек сорый.Башлангыч сыйныф укучысы мөстәкыйль эшләргә, уйнарга, уйларга тырыша. Уеннар барышында үзе үк үзгәрешләр дә кертә ала. Драма түгәрәкләрен оештырып төрле уен элементларын кертергә мөмкин. Һәр сәхнә әсәрен сайлаган очракта баланың яшь үзенчәлеге исәпкә алына. Алар балаларга төрле яктан ачылырга ярдәм итә, акыл,аралашу үсешенә йогынты ясый. Уен сайлаганда балаларда бер- берсенә карата дустанә мөнәсәбәт урнаштыру, төгәл һәм дөрес бәя бирә белү,таләпчәнлек кебек сыйфатлар тәрбияләүне күздә тота.

Халык җырлары - музыка фольклорының иң якты әсәрләре. Алар -эстетик тәрбия чыганагы. Балада эстетик ләззәтләнү,шатлык, канәгатьләнү хисе уяткан һәрнәрсә тәрбияви көчкә ия. Җырлар балаларның иҗади сәләтләрен ачарга ярдәм итә. Укучылар җырлы -биюле уеннарны бик яратып башкаралар. Моңа мисал итеп "Чума үрдәк, чума каз", "Миңлебай","Кәрия-Зәкәрия" һәм башка күп төрле түгәрәк уеннарын алырга була.

Кешеләрнең үз- үзләрен тоту кагыйдәләр җыелмасын тәшкил итүче сөйләм этикеты халыкның мәдәнилек дәрәҗәсен билгели торган иң мөһим өлешләрнең берсе булып тора. Сөйләм әдәбе кагыйдәләре - алар милли традицияләргә һәм гореф- гадәтләргә таяна. Өлкән буын кешеләрендә традицион һәм үзенчәлекле сыйфатлар чагыштырмача чиста һәм ачык булып күренә. Безнең әби - бабайларыбыз, тел һәм әдәбият гыйлемен белмәсәләр дә бала сөйләмендә чит- ят сүзләр буталып йөргәнне яратмаган, саф татарча сөйләшүне таләп иткән. Милләтнең саклануы аның теленә турыдан - туры бәйләнгән. Тукай да өзгәләнеп "И туган тел, и матур тел, әткәм- әнкәмнең теле, дөньяда күп нәрсә белдем, син туган тел аркылы" дип, юкка гына әйтмәгәндер. Шулай ук татарларның сөйләменә ислам диненең тәэсире дә бар. Ә яшьләр сөйләмендә исә рус теле тәэсире сизелә. Хәзергесе мохитта балаларыбыз төрле тәрбия ала. Баланың ата- анасына булган карашы үзгәрүен һәркем күреп тора. Түгәрәк эшчәнлегендә дә балаларның әдәби теленә зур игътибар бирелә.

Драма түгәрәгендә укучылар әдәплелек кагыйдәләре белән бик күп очрашалар. Сөйләм, киенү, өстәл янында, кунак , туганннарга карата әдәплек кагыйдәләрен тыңлап кына калмыйлар,ә бәлки үзләре дә бер- берсенең кимчелекле якларын күрсәтеп, шул кимчелекләрне төзәтү өстендә эшләргә тырышалар.

Халык традицияләрен кулланып уздырылган чаралар баланың актив үсешенә өстәмә чыганак итеп кулланыла

Хәзерге вакытта җәмгыятьтә үзгәрешләр чоры бара. Укытучы алдында шәхеснең акыл эшчәнлеген төрле яклап үстерүне күздә тотып, никадәр яңа алымнар, шартлар, технологияләр барлыкка килде. Шулар арасында милли рухлы хәзинәбез күмелеп калмасын иде. Безнең рухи байлыгыбыз, милли традицияләребез исән.

**Нәфис һәм техник як тан иҗади эшчәнлекне берләштерү**

**Программаның тибы- катнаш.**

**Программа заман таләпләренә туры китереп, норматив чыганакларга карап төзелгән:**

1. Россия Федерациясенең 29.12.2012елгы 273нче номерлы « Россия Федерациясендә белем бирү турында» Федеральный законы;

2. Россия Федерациясенең 04.09.2014елгы 1726номерлы «Балаларга өстәмә белем бирү турындагы Концепциясе» турындагы боерыгы;

3. Россия Федерациясенең 29 май 2015 елгы 996номерлы «Россиядә 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә тәрбия бирү стратегиясе»турындагы боерыгы;

4. Россия Федерациясе Президентының 01.06.2012елгы 761нче номерлы «2012-2017 елларга балаларны яклау исәбеннән милләтләр стратегиясе»турындагы указы;

5. Приказом Минпросвещения России от 09.11.2018 N 196 «Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по дополнительным общеобразовательным программам»;

6. Россия Федерациясе белем бирү министрлыгының 1465/14 номерлы 2014елгы «Күп профильлеОб утверждении Модельного стандарта качества муниципальной услуг по организации предоставления дополнительного образования детей в многопрофильных организациях дополнительного образования в новой редакции.

7. Өстәмә белем бирү программасын проектлау буенча методик тәкъдимнәр.

**Программанын яналыгы**: Әлеге программада драма берләшмәсенә йөрүче укучылар өчен яңалык булып килеп кергән Федераль Дәүләт Белем Стандарты буенча укытуда укучыларның дәрестән тыш эшчәнлеген оештыру буенча эш программасы урын алды.
Укучылар эшчәнлеген оештыруның эстетик - сәнгать юнәлеше - театр **берлэшмэсе** эше тәкъдим ителә.
Укучыларны берлэшмэсе эшенәҗәлеп итү, театр белән кызыксыну, сәнгать әсәрләренә мәхәббәт уяту, укучыларның артистлык сәләтен, иҗади талантларын күрә, уңышларга дәрт уята алуга ирешү, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү максатыннан киң даирәукытучыларына ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.
**Программанын үзенчәлеге:**"Шәхес формалаштыруга юнәлтелгән технология аша укучыларда әдәбиятка-сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләп, иҗади үсешләрен булдыру.
**Максаты:**
Укучыларда милли үзаң тәрбияләү – халкыбыз тарихын яхшы белүче, милләте белән горурланучы шәхесләр тәрбияләү.
**Бурычлары:**
**Белем бирүче:**

1. Чыгыш ясау, аралашуга өйрәтү, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү
2. Укучыга үзенең сөйләм осталыгын, талантын сынап карарга шартлар тудыру, киләчәктә һөнәр сайларга юнәлеш бирү;
3. Әңгәмәдә катнашып, үз фикереңне әйтә белергә өйрәтү.
4. Укучыларны түгәрәк эшенә җәлеп итү, театр белән кызыксыну уяту.
5. Сәнгать әсәрләренә мәхәббәт уяту.
6. Укучыларның артистлык сәләтен, иҗади талантларын күрә, уңышларга дәрт уята алуга ирешү.
7. Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү

1. **Үстерүче:** Чыгыш ясау, аралашуга өйрәтү, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү .

   Укучыга үзенең сөйләм осталыгын, талантын сынап карарга шартлар тудыру, киләчәктә һөнәр сайларга юнәлеш бирү

**Тәрбия бирүче:** 1)Театрның үткәне һәм бүгенгесе белән таныштыру.

2)Театрга нигез салучыларның иҗади эшчәнлеге белән таныштыру.

3)Сәхнәдә үзеңне тоту осталыгын, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү.

4) Сәнгать әсәрләренә мәхәббәт уяту.

**Программаны тормышка ашыруда катнашучы балаларның яшь үзенчәлекләре.**
Программа 5-11 класстагы яшүсмерләр өчен, аларның шул яшьтәге психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән. Бу чорда балалар бик актив, яңалыкка омтылучан булалар. Төркемдәге балалар саны 1 нче елны- 15, икенче уку елында 12, өченче елны 10 кешене берләштерә. Төркемгә керергә теләүче укучылар бернинди әзерлексез кабул ителә. Төркем яшь үзенчәлекләренә карап бүленә.

**Программаны тормышка ашыру этаплары һәм вакытлары:**
**программа 3 елга исәпләнгән:**
1-нче уку елы– 144 сәгать;
2- нче уку елы – 216 сәгать;
3- нче уку елы – 216 сәгать.
Занятиенең формалары:
Телдән: әңгәмә, аңлату;
Күрсәтмә: рәсемнәр, иҗади проектлар презентарациясе:
практик занятие: мастер класслар.
Эвристик: киләчәккә эш төрләре уйлау .
Занятиенең режимы: 1- нче уку елы –атнага 2 тапкыр, 2шәр сәгать;
2- нче уку елы- атнага 3тапкыр, 2шәр сәгать;
3- нче уку елы- атнага 3тапкыр, 2шәр сәгать;

**Көтелгән нәтиҗә:**
- сәхнәдә үзеңне иркен тоту, фикереңне өздереп әйтү формалаша;
- музыкаль әсәрләрне башкару осталыгының үсүе;
-татар халык авыз иҗатының жанр төрлелеге белән танышып бару;
- Туган якка карата мәхәббәт тәрбияләү, җырлар, шигъри әсәрләрне өйрәнү;
Укучылар коллектив булып формалашып бетә;
-йомгаклау этабы буларак барлык өйрәнгән темалар буенча белем туплана;
-татар халык авыз иҗатының жанр төрлелеге белән тулаем танышып бетерү;
- туган як темасын дәвам итү;
- сәхнә әсәрләрен өйрәнү;
- укучыларда сәхнәдә иркен тоту күнекмәсе формалаша;

**Эшчәнлек формасы:** Түгәрәк эшчәнлеге практик дәресләр формасында,әңгәмә формасында тормышка ашырыла.Тәрбияви максатка күргәзмәләр оештыру нигезендә ирешәбез.

Кадрлар белән тәэмин итү: әлеге программа буенча белем бирү процессын оештыручы педагоглар югары яки урта һөнәри белемгә ия булырга тиеш

**Педагогик яктан контроль: Программаны үзләштерүнең нәтиҗәсе төрле тикшерүләр ярдәмендә билгеләнә:агымдагы контроль, йомгаклау контроле.**

Балаларның эшчәнлеген билгеләүнең төп күрсәткече булып аларның сәнгатьле сөйләмнәре, артистлык осталыгы,иҗади эшчәнлекләре тора.

**Укыту планы 1 нче ел**

| № | Тема | Сәгать саны | | | Тикшерү формасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Теорит. | Практик | Барлыгы | |
| **1** | Әнәс Хәсәнов ”Әти диясем килә” | 4 | 40 | 44 | Төркем белән эш |
| **2** | “Үги кыз “ әкияте | 2 | 30 | 32 | Чыгыш ясау |
| **3** | “Кәҗә белән сарык” | 2 | 24 | 26 | Практик эш |
| **4** | “Озын толым” | 1 | 7 | 8 | Төркем белән эш |
| **5** | “Нәүрүз” бәйрәме “Каз өмәсе” | 2 | 14 | 16 | Экскурсия |
| **6** | Мөнәҗәтләр | 3 | 15 | 18 | Практик эш |
| | **Барлыгы** | 14 | 130 | 144 | |

**Укыту планы 2 нче ел**

| № | Тема | Сәгать саны | | | Тикшерү формасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Теорит. | Практик | Барлыгы | Тикшерү формасы |
| **1** | Театр – яктылыкка, нурга илтә | 12 | 36 | 48 | Төркем белән эш |
| **2** | Сәхнә әсәрләре | 15 | 35 | 50 | Чыгыш ясау |
| **3** | Театр тарихыннан | 10 | 30 | 40 | Практик эш |
| **4** | Татар халык авыз иҗаты | 9 | 25 | 34 | Төркем белән эш |
| **5** | Туган ягым яшел бишек | 8 | 34 | 42 | Экскурсия |
| **6** | Йомгаклау | 1 | 1 | 2 | Практик эш |
| | Барлыгы | 55 | 161 | 216 | |

**Укыту планы 3 нче ел**

| № | Тема | Сәгать саны | | | Тикшерү формасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Теорит. | Практик | Барлыгы | |
| **1** | Театр һәм без | 2 | 6 | 8 | Төркем белән эш |
| **2** | Туган ягым минем | 6 | 18 | 24 | Чыгыш ясау |
| **3** | Кичәләр бәйләме | 7 | 31 | 38 | Практик эш |
| **4** | Спектакль уйныйбыз | 15 | 35 | 50 | Төркем белән эш |
| **5** | Милли йолалар | 3 | 12 | 15 | Экскурсия |
| **6** | “Театр ” конкурсына театр | 6 | 30 | 36 | Практик эш |
| **7** | Җырлы-биюле уеннар | 4 | 18 | 22 | Төркемдә эш |
| **8** | Балачак илендә | 4 | 19 | 23 | Практик эш |
| | **Барлыгы** | 47 | 169 | 216 | |

**1нче уку елы программасы эчтәлеге**

**Әнәс Хәсәнов ”Әти диясем килә”(44 сәгать)**

Әсәрне бергәләп укып чыгу. Эчтәлеген тирәнрәк аңлау, катнашучылар сөйләме аша аларның холкын билгеләргә өйрәнү.Аңлатмалар биреп пьесаны анализлау. Тикшерү беренче пәрдә яки андагы берничә күренешне бергәләп күзәтүдән кичерүдән башлана.

Һәрдаим дикция, сәнгатьлелек өстендә эшләү;

**“Үги кыз “ әкияте (32 сәгать). “Кәҗә белән сарык” әкияте (26 сәгать).**

Әкиятнең эчтәлеге белән танышу. Эзлекле рәвештә әкиятнең эчтәлеген үзләштерү. Аерым өлешләр, вакыйгалар турында фикерләр әйтү. Уңай образларның төп сыйфатларын билгеләтү. Тискәре образларның характерлы билгеләрен күрсәтү. Тамашачыларга уңай һәм тискәре образлар арасында тоган ата образын күрсәтә белүләренә ирешү. Халык авыз иҗатын дөрес файдалану. Фольклорның жанрларын өйрәнү. Әкиятләр төрләре белән таныштыру, әкиятләр алып килеп, аны анализлау

**“Озын толым” (8 сәгать)**

Татар халык биюләре үзләренең нәфислеге һәм затлылыгы, биючөнең зирәклеге һәм кыюлыгы белән күңелне әсир итә. “Каз канаты”, “Челтәр элдем читәнгә” җырлары көйләренә бию элементлары уйлау. Аларны камилләштерү.

“**Нәүрүз” бәйрәме**.(16 **сәгать**)

Татар халкының милли бәйрәмнәрен искә төшерү. Алар турында мәгълүмат бирү.

**Каз өмәсе**

Татар халкы борынгы заманнарда ук каз асраган. Казмамыгыннан йомшак мендәр, җылы түшәк ястык ясаганнар. Каз итеннән тәмле ашсу пзерләгәинәр. Каз бәлеше, каз коймагы, каз табипмәге, каклаган каз -берсеннән-берсе тәмлерәк ризыклар. Каз өмәләре авылның иң күңелле вакыйгасы булган.

Бу көнне бер йортта каз суялар. Авыл кызлары шул йортка җыелалар һәм каз мамыгы йолкыйлар. Эш шаян сүз, матур җыр, күңелле уеннар белән бара. Аннары кызлар казларны көянтәгә асалар дә чишмәгә китәләр.

Казларны салкын чишмә суында юалар. Аларга егетләрдә булышалар.

Менә эш бетә. Мәҗлес башлана.Табынга майлы коймак, тәмле чәй чыга. Аннары яшьләр күңелле уеннаруйныйлар.

**Мөнәҗәтләр(18 сәгать)**

Мөнәҗәтләрсүзенә төшенчә бирү, мәгънәсен аңлату. Мөнәҗәтләрне көйләп күрсәтү.

Районнан чыккан бәетләрне уку, тыңлау.

Әкиятләрне сәхнәләштерү өстендә эшләү. Рольләргә бүлү. Төп геройләрның холыклары билгеләү. Декорация уйлап табу. Аларны әзерләү. Катнашучы геройларга киемнәр табу, тектерү.

**2нче уку елы программасы эчтәлеге**

**I. Театр – яктылыкка, нурга илтә.** 48 сәг.

Кереш. Укучыларны туплау, түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. Инструктаж үткәрү. Түгәрәкнең эшчәнлеге белән таныштыру..Әлеге уку елына куелган максат, бурычлар белән таныштыру

**II. Сәхнә әсәрләре** 50сәг.

Сәхнә серләренә өйрәнү. Кечкенә күләмле сәхнә әсәрләре өстендә эшләү. Аларны башкару осталыгы, рольләрне башкару, костюмнарны дөрес сайлау серләренә өйрәнү.

Татар халык иҗаты белән танышу. Татар халык иҗатының үзенчәлекләрен билгеләү. Индивидуаль рәвештә җырлар, биюләр өйрәнү. Киемнәр әзерләү.

**III.Театр тарихыннан-40 сәг.**

Беренче барлыкка килгән театрлар тарихы белән танышу. Күрсәтелгән сәхнә әсәрләре, афишалар, куелган урыннары, вакыты белән таныштыру. Беренче театр артистлары. Портретларын, слайдлар карау. Г.Камал “Беренче театр” әсәрен карау. Фикер алышу. Сәхнәләштерү.

**IY.Татар халык авыз иҗаты** -34 сәг.

Татар халык иҗатының жанрлары белән таныштыруны дәвам итү. Татар халык иҗатының үзенчәлекләрен билгеләү. Индивидуаль рәвештә җырлар, биюләр өйрәнү. Киемнәр әзерләү. Сәнгатьле сөйләү өстендә эшләү. Телнең сөйләү үзенчәлеген өйрәнү.

**Y.** Туган ягым – яшел бишек. 42 сәг

Районыбыздан чыккан якташ артистларыбыз белән танышу. Алар турында мәгълүматлар туплау. Алар уйнаган спектакльләрнең видеоларын карау. Альбомнар төзү.

**Йомгаклау** -2сәг.

Ел буена өйрәнгәннәрне кабатлап чыгу, нәтиҗә ясау. Туган шәһәрне өйрәнүне дәвам итү. Туган ягың белән горурлану хисе, аның үсешенә үз өлешеңне кертү, үстерү тәрбияләү. Туган шәһәр турында язылган шигъри әсәрләр, җырлар башкару, өйрәнү.

**3нче уку елы программасы эчтәлеге**

**I. Театр һәм без.**-8сәг.

Түгәрәкнең эшчәнлеге белән таныштыру. Инструктаж үткәрү.Әлеге уку елына куелган максат, бурычлар белән таныштыру **.**Уку елында утеләчәк тамалар исемлеге белән танышу. Сәхнә әсәрләре белән танышу

**II.Туган ягым минем** -24сәг.

«Туган илем бер генэ…» Туган як, җир турында язучылар язган әсәрләрне уку, фикер алышу.Татарстан гимны, дәүләт символлары белщн таныштыру. «Мин яши торган урам, йорт». Кечкенә сәхнә әсәрләрен өйрәнү. Үзең яшәгән йортың турында сөйләү. Авыл бәйрәмнәре, урам җыеннары белән таныштыру.

**Ш. Кичәләр бәйләме-38сәг.** Халык мәдәнияте - ул милләтебезнең йөзе, рухи хәзинәсе, җәмгыятьнең байлыгы . Әкиятләр кичәсе: кечкенә күләмле сәхнә әсәрләрен сәхнәләштерү, кичәләр-бәйрәмнәр уздыру.Слайдта биюләрнең башкару осталыгын карау, фикер алышу. Милли биюләр өйрәнү. Татар биюе. Милли йолалар уздыру.

**IV. Спектакль уйныйбыз. (50 сәг.)**

Э.Шәрифуллина “Без сезне көтәбез,сүнмәсен аралар”

әкият-пьесаның эчтәлеге белән танышу. Рольләргә бүлеп уку.

Спектакльне кабатлау. Музыка. Декорация. Киемнәр әзерләү. Яңа ел бәйрәмендә театр-тамашаны кую. Композиторлар. Татар җыр сәнгатендә күренекле композиторлар

**V. Милли йолалар. (15сәг.)**

"Хәтердән башка йолалар, тәрбиядән башка рухи хәзинә, рухи хәзинәдән башка шәхес, ә шәхестән башка халык - тарихсыз"- дип әйтелә халыкта. Халкыбызның гореф-гадәтләре, аларның милли үзенчәлекләре.

Каз өмәсе. Орчык өмәсе. Өй күтәрү өмәсе. Табигать һәм без. Туган ягыбыз- Әлки төбәгеннән чыккан данлыклы кешеләр тормышы белән танышу**.** Милли бәйрәм -Сабан туе. Сабан туе уеннары, җырлар, биюләр башкару. Милли йола “Каз өмәсе- авыл бизәге”. Слайдлар карау

**VI. “Театр ” конкурсына театр. (36 сәг.)**

Театр атналыгы оештыру (атналык программасы аерым төзелә). “Театр ” конкурсында катнашу өчен Г. Рәхим “Кәҗә белән Сарык”, танышу, рольләр бүлешү әкият-пьесасы белән танышу белән чыгышка әзерләнү. Г. Исхакый “Җан Баевич”комедиясен сәхнәләштерү

Балалар өчен язылган җырлар тыңлау (кассета, караокедан). Иң матур җырларны өйрәнү, сәхнәдә башкарырга (аерым, күмәк) әзерләнү. Җырга карата киемнәр сайлау.

Кызлар-малайлар белән парлы вальс өйрәнүне дәвам итү.

**VII. Җырлы-биюле уеннар. (22сәг.)** Кешелек туплаган рухи байлык, әдәп- әхлак кагыйдәләрен үтемле итеп җиткерү өчен әби- бабайларыбызның, төрле авырлыклар белән яшәүләренә карамастан сынмавы, сабыр , инсафлы, мәрхәмәтле булып калуын җиткерү кирәк. Бу максаттан халкыбыз бәйрәмнәре- шәхесне иҗтимагый тормыш таләпләренә күнектерү чарасы. Алар һәр кешенең йөрәк түрендә саклана, үз туган ягына тарта “Талы-талы”,”Без, без,без идек” **,** “Яңгыр”, “Су юлында”, “Биесәнә” уеннарын уйнау.Такмакларәйтешү.

**VIII. Балачак илендә (23сәг.)** Бала күңелен ап- ак кәгазь белән чагыштыралар. Шул кәгазьгә ничек итеп матурлык, шәфкатьлелек бөртекләрен чәчәргә соң? Әлбәттә, әдәбият- сәнгать аша. Әдәбият , сәнгать белән кызыксынган , китапларны чын күңеленнән яратып укыган баланың белеме дә тирәнрәк, күңеле дә баерак була.Аның күркәм эшләр башкарырга омтылышы да көчәя. Балачак турында җырлар тыңлау, башкару, балалар тормышыннан кечкенә сәхнә әсәрләре башкару, “Кояшлы ил-безнең ил” фильмнар карау, сәхнә әсәрләрен кабатлап чыгу.

**Материаль - техник тулыландыру:**

- төрле төрдәге бәйге, ярышлар өчен оптималь мөмкинлекләр булдыру;
- укучыларның иҗади эшләре өчен җирлек тудыру;
- аудиоматериал һәм видеотехника;
- компьютер;
- телевизор;
- проектор,экран һәм башкалар;

**Укытучының кулланма әдәбияты**


1. “Әдәбият белеменә кереш” 1998 ел

2. Татар халык әкиятләре. 1997 ел
3. “Җырлыйк әле” җыр китабы. 1997 ел
4. Х. Халиков “Зиһен ачкычлары” 2001 ел
5. “Мәктәп сәхнәсе” китабы.
6. Табышмаклар, тизәйткечләр, тел шомарткычлар. 1997 ел
7. “Көмеш кыңгырау”, “Сабантуй” газеталары.
8. Гомәр Бәширов “Туган ягым – яшел бишек”. 1986 ел
9. “Әдәплелек дәресләре”.
10. Вагыйзов С.Г., Вәлитова Р.Г. Башлангыч мәктәптә татар телен укыту методикасы – Казан: Мәгариф,2001.
11. Вагыйзов С.Г. Кызыклы грамматика – Казан; Татарстан китап нәшрияты, 1980 ел.
12. Зиннурова Ф.М. Бала сөйләмендәге кимчелекләрне төзәтү – Казан: Мәгариф, 2005.
13. Низамов А.М. Милли мәктәп.
14. Тәрбия нигезләре – Казан: Мәгариф,2005.
15. Хуҗиахметова Ә.Н. Тәрбия мәңгелек “фәлсәфә” – Казан: Мәгариф, 2001.
16. Шәймарданов Р.Х., Сибгатуллин Р.Г. Татар милли педагогикасы –Казан: “Матбугат йорты” нәшрияты, 2000.
17. “Мәгариф”, “Сөембикә”, “Ялкын” журналлары
18. “Мәктәп сәхнәсе” сериясеннән китаплар.

**Кадровое обеспечение:** занятия по дополнительной общеобразовательной программе: «Татар драмма фольклоры» ведет специалист с высшим образованием Фаттахова М.Г. , стаж пед.работы 36лет . По образованию – учитель татарского языка и литературы , КПИ, 1994 г.

**Формы аттестации/контроля**

Контроль знаний проводится в виде зачета, который может включать в себя : тестирования, практические задания, защиты творческих работ.

| **Виды аттестации** | Формы оценки результативности | Срок проведения |
|---|---|---|
| **Промежуточная аттестация** | Диагностика уровня ключевых, мета предметных и предметных компетенций учащихся.<br>Формы- зачет ( тестирование, практическая работа) | Декабрь, май (кроме последнего года освоения программы) |
| **Аттестация обучающихся по завершению освоения программы** | Оценка качества обученности учащихся по завершению обучения по образовательной программе<br>Формы – зачет (тестирование, практическая работа) | Май последнего учебного года освоения программы |

Для отслеживания результатов реализации программы применяются различные методы: анкеты, тесты, выставки, защиты творческих работ и т.д.

Так же проводится педагогическое наблюдение. Каждый ребенок в течение календарного года принимает участие в конкурсах, выставках различного уровня, начиная от участия в выставках объединения и заканчивая районными, региональными и всероссийскими конкурсами.

**Укучылар өчен әдәбият**

1.“Мәктәп сәхнәсе” сериясеннән китаплар.
2.Татар әдәбиятыннан хрестоматияләр, 5-9 сыйныф, Казан, ”Хәтер”нәшрияты,1999.
3.Әдәплелек дәресләре (хрестоматия). Фәнни редакторы профессор Р.А.Низамов. Казан: Мәгариф, 2000.
4.Могҗизалы мәктәп сәхнәсе.Казан:Мәгариф,2003.
5.”Мәктәп китапханәсе” сериясе томлыклары.
6.”Энҗе чәчтем” сериясеннән фольклор җыентыклары.
7.Татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия.Төзүче- авторлары Л.И.Минһаҗева,И.И.Мияссарова,Казан-“Хәтер” нәшрияты,2004

8.Татар халык әкиятләре.
9.Табышмаклар.
10.Мәкальләр.

**Укытучы өчен әдәбият исемлеге**

Төп әдәбият

- С.Г.Вагыйзов, Р.Г.Вәлитова. «Кызыклы грамматика».Казан «Мәгариф» 2009
- Хатипов Ф.М. Әдәбият теориясе. – Казан: Мәгариф.
- Хөсни Ф. Ни әйтергә? Ничек әйтергә? – Казан: Таткитнәшр.
- Абдуллина Р.С. Стилистика һәм сөйләм культурасы мәсьәләләре. Яр Чаллы.
- Йосыпов Р. Сөйләшү әдәбе. Казан утлары журналлары..
- Саттаров Г.Ф. Татар телендә шәхескә олылап эндәшү. Казан. Татарстан китап нәшрияты.
- Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. Казан. "Мәгариф" нәшрияты, 2005.
- Сәлимов Х.Х. Татар теленең орфоэпик сүзлеге. Чаллы, "Камаз" нәшрияте, 2005.
- Хангилдин В.Н. Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре. Казан. "Мәгариф" нәшрияты.
-

Өстәмә әдәбият

- Н.С. Гыймадиева «Дәрестә һәм дәрестән соң» Казан, 2004.
- С.М. Трофимова «Татар теле һәм әдәбияты укытучысына» Казан, 2005.
- Ф.С. Сафиуллина «Учат таблицы и схемы» Казан.
- Л.К. Хөснетдинова «Әдәбият укыту мәсъәләләре» Яр Чаллы, 2009.
- Хангилдин В.Н. Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре. – Казан: Тат.кит.нәшр.
- Юсупов Р.А. Укучыларда сөйләм культурасы тәрбияләү. – Казан: Тат.кит.нәшр.
- С.Г.Вагыйзов “Кызыклы грамматика” “Мәгариф” нәшрияты

Укучылар өчен әдәбият.

1. Вәлиуллина Р.Г., Нигмәтҗанова Ф.М. Эшлекле татар теле.- Казан. 2004.
2. Татар теленең орфографик сүзлеге. Казан. Татарстан китап нәшрияте.
3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 том. Татарстан китап нәшрияте, Казан.
4. Русча-татарча, татарча-русча сүзлекләр.
5. “Салават күпере”, “Ялкын”, “Мәгариф” журналлары, “Көмеш кыңгырау”, “Сабантуй” газеталары.
6. **Интернет – ресурслар.**
7. http://минобрнауки.рф/ РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы
8. https://mon.tatar.ru/ ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы
9. http://. belem.ru
10. http://www.tatknigafund.ru/ таткнигофонд
11. https://edu.tatar.ru/page2601.htm/cors/ Татар теленнән цфрлы белем бирү ресурслары
12. http://www.balarf Тавышлы интерактив мультимедия китапханә
13. http://tatarz.ru/load/ Татар сайты
14. http://tatarile.org/tatartele/user/register Татар иле
15. http://tatar.org.ru/ Татар виртуаль гимназиясе
16. http://www.akiat.ru/ Татар әкиятләре
17. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары сайты

**Календарь- укыту графигы ( 1 нче укыту елы ,144сәг) 2018-19 нчы уку елы**

| № | Ай исем | Число | Үткәрү вакыты | Дәрес төре | Сәг. саны | Тема | Үткәрү урыны | Тикшерү төре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | е | | | | | | | |
| | Сентябрь | 4.09 | | әңгәмә | 2 | Түгәрәк планы белән таныштыру, оештыру эшләре. | 13 кабинет | |
| | | 6.09. | | әңгәмә | 2 | Татарстанда Дәүләт театры турында кереш әңгәмә | Актлар залы | тестлар |
| | | 11.09 | | әңгәмә | 2 | Габдулла Кариев һәм “Сәйяр” труппасы эшчәнлеге | 13 кабинет | тестлар |
| | | 13.09 | | әңгәмә | 2 | Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин һәм татар театры | Актлар залы | тестлар |
| | | 20.09 | | әңгәмә | 2 | Галиәсгар Камал һәм аның “Беренче театр” комедиясе | Актлар залы | Инд.эш |
| | | 22.09 | | әңгәмә | 2 | “Беренче театр” комедиясен сәхнәләштерүгә әзерлек | 13 кабинет | Инд.эш |
| | | 27.09 | | әңгәмә | 2 | “Беренче театр” комедиясе өчен костюмнар һәм сәхнә бизәлеше өчен декорация әзерләү | Актлар залы | Инд.эш |
| | | 29.09 | | Диалогик сөйләм | 2 | “Беренче театр” комедиясен 5-11нче сыйныф укучылары алдында күрсәтү | Актлар залы | Инд.эш |
| | | 30.09 | | Рольле уен | 2 | Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театры турында белем туплау | 13 кабинет | тест |
| | октябрь | 3.10 | | Рольле уен | 2 | Галиәсгар Камал театрында эшләүче күренекле сәхнә осталары, режиссеры һәм композиторлар турында белемнәре баету | Актлар залы | Төркем.эшләү |
| | | 7.10 | | Рольле уен | 2 | Театр белән хезмәттәшлек итүче драматурглар: Туфан Миңнуллин, Аманулла, Зөлфәт Хәким иҗатлары турында фикер алышу | 13 кабинет | Мөст.эш |
| | | 10.10 | | әңгәмә | 2 | “Син театр турында нәрсәләр беләсең?” темасына викторина уздыру | Актлар залы | Мөст.эш |
| | | 14.10 | | әңгәмә | 2 | Галиәскар Камал исемендәге Татар дәүләт академия, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрларына багышлап презентацияләр төзү | 13 кабинет | Мөст.эш |
| | | 17.10 | | әңгәмә | 2 | Татар театры үсеше. Татар артистлары | Актлар залы | Мөст.эш |
